Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

23.01.2025 Менделеевск ш. № 42

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районында
граждан оборонасын оештыру һәм алып
бару турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында"2024 елның 29 маендагы 125-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» Федераль законның 16 һәм 18 статьяларына ярашлы Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2023 елның 29 августындагы 509 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында граждан оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәнең 15.2 пунктының 2 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәгечә бәян итәргә:

«халыкка хәбәр итү системаларын, шул исәптән халыкка хәбәр итүнең муниципаль һәм локаль системаларын куллануга даими әзерлек хәлендә булдыру, реконструкцияләү һәм тоту;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында (www.mendeleevsk.tatarstan.ru ) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, инфраструктура үсеше һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы А.Ф. Исхаков